КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 август г.Казань № 945

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 28 июнь, 505 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе расходларын түләү буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе расходларын түләү буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 28 июнь, 505 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 1 сентябрь, 940 нчы; 2023 ел, 6 март, 212 нче; 2023 ел, 29 май, 652 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе расходларын түләү буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның унберенче абзацында «гомумтаралган файдалы казылмалардан» сүзләреннән соң «һәм эчә торган минераль сулардан» сүзләрен өстәргә;

3.1 пунктның ундүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Заявка бирүче вәкаләтле оешмага шулай ук түбәндәге документлар күчермәләрен бирергә хокуклы:

заявка бирелә торган айның 1 нче көненә карата Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон формада бирү форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турында салым органының белешмә кәгазе;

Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүче, җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче яки салым агентының бердәм салым түләве сыйфатында күчерелгән акча суммасының кемгә каравы турында белешмә кәгазе формасын һәм аны электрон рәвештә бирү форматын раслау хакында» 2022 елның 30 ноябрендәге ЕД-7-8/1129@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча 2023 елның 1 гыйнварыннан заявка бирелә торган айның 1 нче көненә кадәрге чорга бирелгән салым түләүче, җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче яки салым агентының бердәм салым түләве сыйфатында күчерелгән акча суммасының кемгә каравы турында салым органының белешмә кәгазе;

заявка бирелә торган айның 1 нче көненә Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрыннан өземтә;

заявка бирелә торган айның 1 нче көненә Юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

вәкаләтле орган белән индустриаль (сәнәгать) парк территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү.

Заявка бирүче тарафыннан әлеге пунктта күрсәтелгән документлар бирелмәгән очракта, вәкаләтле оешма әлеге мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, яки ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә, яки документларны вәкаләтле органга бирү турындагы рәсми сорау буенча ала.»;

5.4 пунктта «алтынчы» сүзен «өченче» сүзенә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаның унберенче абзацында «гомумтаралган файдалы казылмалардан» сүзләреннән соң «һәм эчә торган минераль сулардан» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин